| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.11.2024 Казан ш. № 675-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Законнардагы үзгәрешләргә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре
министрлыгының
21.11.2024 № 675-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 26.05.2022 № 308-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6 пункт белән тулыландырырга:

«2.3.6. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында Министрлык карары, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

боерыкның, карарның номеры һәм датасы;

боерык, карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

юридик зат атамасы;

боерык, карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (боерык, карар электрон имза белән имзаланганда).»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру буенча килешү эшләрен яраштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 31.05.2022 № 315-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру буенча килешү эшләрен яраштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.6. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру буенча килешү эшләрен яраштыру турында карарлар Министрлык боерыгы рәвешендә кабул ителә.

2.3.7. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру буенча килешү эшләрен яраштыру турында карар, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру буенча килешү эшләрен яраштыру турында карар, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар электрон имза белән имзаланганда).»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

Регламентка кушымтаның (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасында дүртенче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлеге мөдире | 221-40-25 | Larisa.Shkalikova@tatar.ru». |

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тартып алу буенча килешү эшләрен яраштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 31.05.2022 № 317-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тартып алу буенча килешү эшләрен яраштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.6. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тартып алу буенча килешү эшләрен яраштыру турында Министрлык карарлары Министрлык боерыгы рәвешендә кабул ителә.

2.3.7. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тартып алу буенча килешү эшләрен яраштыру турында Министрлык карары, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне тартып алу буенча килешү эшләрен яраштыру турында Министрлык карары, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар электрон имза белән имзаланганда).»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы гамәлдән чыгарылу турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында” 31.05.2022 № 318-пр Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы гамәлдән чыгарылу турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентында:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6 пункт белән тулыландырырга:

«2.3.6. Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы гамәлдән чыгарылу турында карар яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы гамәлдән чыгарылу турында карар яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар электрон имза белән имзаланганда).»;

3.6.2 пунктта «Бердәм портал,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

Регламентка кушымтаның (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасында «Җир ресурслары идарәсе башлыгы» дигән дүртенче юлны төшереп калдырырга.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 585-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 11.04.2024 № 206-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип таныргa;

Регламентка кушымтаның (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасында дүртенче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлеге мөдире | 221-40-25 | Larisa.Shkalikova@tatar.ru». |